# Бәзәкәдә сабантуе

9 июньдә Бәзәкәдә халкыбызның иң яраткан бәйрәме сабантуй булачак. Сабантуй 10.00 сәгатьтә бәйрәмнең йөзек кашы булган ат чабышлары белән башланып китәчәк. Ярышлар “Бәзәкә атлары” һәм “Кунак атлары” номинацияләрендә үтәчәк.

11.00 сәгатьтә мәйданда сабантуйны тантаналы ачу булачак. Сабантуй программасында кыр батырларын бүләкләү, төрле халык уеннары, көрәш һ.б. булачак. Шулай ук сугышта һәлак булган авылдашыбыз герой-очучы Гильфанетдинов Сөләйман Авзал улының 82 ел элек бирелми калган Сугышчан Кызыл Байрак орденын туганнарына тапшыру булачак.

Сабантуйга махсус кунак Татарстанның һәм Башкортостанның халык артисты **Айдар Галимов** үзенең иҗат төркеме белән көтелә.

Авылдашлар, якташлар, хөрмәтле кунаклар! Сабантуйга рәхим итегез, туганнарыгыз, балаларыгыз, оныкларыгыз, дусларыгыз белән бергә рәхәтләнеп ял итегез!